# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлеге Карары

2018 елның 24 августы 18№

Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлеге Советының 2018 елның 19 мартындагы «Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлегендә җәмәгать тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында» 6 номерлы карарына өстәмәләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлеге Уставы нигезендә Әлки муниципаль районының Иске Кората авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Әлки муниципаль районы Иске Коратаавыл җирлеге Советының 2018 елның 19 мартындагы «Әлки муниципаль районы Иске Кората авыл җирлегендә җәмәгать тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында» 6 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

   - 3 статьяның 2 пунктындагы 3 пунктчасында “, Федераль законның 13 статьясы нигезендә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән йә гражданнар җыеннарында белдерелгән муниципаль берәмлек ризалыгын алу таләп ителә торган очраклардан тыш.» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

Иске Кората авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: Н.В.Кузнецов